**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8099**
**13.12.2021**

Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 6 апрелендәге 1695 номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 5229 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 7278 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы 2191 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге 4177 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасының 6 бүлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «№ т/б | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару срогы (ел саен) | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 (база) | 2020 кеше | 2021 кеше | 2022 кеше | 2020 (мең сум) | 2021 (мең сум) | 2022 (мең сум) |
| 9. | Халыкара инвалидлар көненә багышланган спорт һәм мәдәни-масскүләм чаралар үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитет | 1–10 декабрь | Кеше саны | 1 200 | 1 200 | 1 200 | 1 200 | 178,93 | 310,00 | 210,00»; |

2) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № т/б | Чараның исеме | Башкаручылар | Башкару срогы (ел саен) | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләүнең индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 (база) | 2020 кеше | 2021 кеше | 2022 кеше | 2020 (мең сум) | 2021 (мең сум) | 2022 (мең сум) |
| 16. | Инвалидларны, инвалид балаларны сәнгать иҗаты аша җәмгыятькә социаль җайлаштыру чаралары үткәрү:<br>1) Инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең район турлары;<br>2) Инвалид балаларның сәнгать иҗаты шәһәр фестиваленең гала – концерты | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвамында | Кеше саны | 450 | 750 | 750 | 750 | 182,31 | 90,00 | 190,00»; |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов